**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 127** **28.03.2024 ел**

**Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 маендагы 100 номерлы «Кадер авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары нигезендә территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 маендагы 100 номерлы «Кадер авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл авыл җирлеге башлыгы** **Л.Н. Барсукова**